Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл жирлегенең
Көшкәтбаш торак пунктында
ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

«25» март, 2024 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге Уставының 25 маддәсе нигезендә Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлегенең Көшкәтбаш торак пунктында халык жыены карар бирде:

1. 2023 елның 30 ноябрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлегенең Көшкәтбаш авылы торак пунктында гражданнар жыены №2 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 нче пункт түбәндәгечә расларга:

«2. Алынган акчаны түбәндәге эшне башкарып җирле әһәмияттәге проблемаларны чишү өчен кулланырга:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Көшкәтбаш авылында Мельничная, Х.Такташ урамнары буенча юлларны ремонтлау).

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлегенең Көшкәтбаш авылы торак пунктында гражданнар җыенына үзгәрешләр кертү буенча 30.11.2023 ел, №2 карарны кабул итү.

3.Югары Субаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә baltasi.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталы (pravo.tatarstan.ru).

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү һәм җибәрү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Югары Субаш авыл җирлеге
муниципаль берәмлек башлыгы
Совет рәисе, Гражданнар җыенында рәислек итүче ________ А. А. Хөснетдинов